| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«30» октября 2024ел № 137

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карарына (08.07.2024 № 82 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) күрсәтелгән карар белән расланган МКУ «Теләче муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. МКУ «Теләче муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33700 |

| | |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31500 |
| Бүлек башлыгы | 27700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 25300 |
| Бухгалтер | 24000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны 5 берәмлектән дә ким булмаска тиеш.»;

Б) күрсәтелгән карар белән расланган, Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең Башкарма комитетларының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | - | 27000 сум |
| Бухгалтер | 24500 сум | 24500 сум». |

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин